Темников районы Лесное Цибаево авылында алтынчы мәртәбә «Цибайча кәбестәләр» Тобәкара гастрономия фестивале узды. Бу вакыйга Россиянен торле почмакларыннан менләгән кунак һәм катнашучыларны жәлеп итте. Татарларыбыз да бу бәйрәмне vз итә.

Фестиваль тантаналы рәвештә ачылды. Аннары кунаклар бәйрәмчә бизәлгән мәйданчыклар, интерактив зоналар һәм тәмле ризыклар атмосферасына чумдылар. Чаранын топ геройлары халык коллективлары һәм башкаручылар булды. Гастрономиядән тыш, кунакларга мавыктыргыч мастер-классларга барырга, конкурсларда катнашырга тәкъдим иттеләр. Шул исәптән активлар арасында Тарханлылар, Митряллылар (фотода) булдылар. Тосле фотозоналар һәм сувенирлар ярминкәләре халык бәйрәме картинасын тулыландырды.

«Цибайча кәбестәләр» халыкара дуслыгы vрнәге булды.